РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Буа шәһәре

22 нче февраль 2018нче ел № 5-29

Татарстан Республикасының Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексын яңа басмада раслау турында

Татарстан Республикасы Президенты Указын “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексын раслау турында” 29 ноябрь 2014 ел №УП-1100 тәңгәлләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 4 апрелендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының рәсми сайтлары бүлекләрен “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча тутыруга Бердәм таләпләрне раслау турында” карары нигезендә, Татарстан Республикасының Буа муниципаль районы Уставының нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

**карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасының Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексының яңа басмасын расларга.
2. Буа муниципаль районы Советының 22.12.2011, № 4-7 һәм 16.12.2014 № 9-43 “Буа муниципаль районыны җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләрнең этика һәм хезмәт тәртибе кодексы” турындагы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Татарстан Республикасының Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә әлеге Кодекс мәгълүматларына таянып эш итәргә һәм карар белән танышуны тәэмин итәргә.
4. Җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

-муниципаль хезмәткәрләр этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексын эшләргә һәм расларга;

-муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт килешүләренә муниципаль хезмәткәрләр этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексын бозган өчен җаваплылык турындагы нигезләмәләрне кертергә.

5. Татарстан Республикасы Буа муниципаль идәрәсе вазыйфаларын вакытлыча биләүче затларга Татарстан Республикасының Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексының әлеге затлар хокукый статусына каршы килмәгән өлешендәге нигезләмәләрен үтәүне тәкъдим итәргә.

6. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтында bua@tatar.ru. урнаштырып халыкка җиткерергә.

7. Әлеге Карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

8. Әлеге Карарны үтәүне контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Буа муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе А.М. Алимовага йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы
һәм муниципаль район Советы рәисе М.А. Җаббаров

Кушымта
Буа муниципаль район Советы
Карары № 5-29 22.02.2018нче ел

**Татарстан Республикасының Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексы яңа басмада**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасының Буа муниципаль районның җирле үзидарә органнарына гражданнарның муниципаль хезмәткәрләрнең ышаныч абруен ныгытуга ярдәм итү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр үз һөнәри эшчәнлеген лаеклы үтәү, хезмәт тәртибе этик нормаларын һәм кагыйдәләрен билгеләү максатларында, Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы федераль закон нигезләмәләре «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 нче елның 25 нче декабрендәге №273-ФЗ номерлы федераль законнар, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” гы 2 нче март 2007 нче ел № 25- ФЗ Федераль Законы, Россия Федерациясе Президентының 2002 нче елның 12 нче августындагы №885 “Дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенең гомуми принципларын раслау турында” Указы, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында Кодексы 25нче июнь, 2013нче ел, №50-ТРЗ нигезендә Татарстан Республикасының Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексы эшләнде.

2. Кодекс һөнәри хезмәт этикасының һәм хезмәт урынында тәртипнең төп кагыйдәләренең гомуми принциплары җыелмасыннан гыйбарәт, били торган вазыйфасына бәйсез рәвештә, Татарстан Республикасының Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре шуларга таянып эш итәргә тиеш.

3. Россия Федерациясе гражданины,Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы учреждениеләренә эшкә керүче гражданин Кодекс нигезләмәләре белән таныша һәм аларны үзенең һөнәри эшчәнлеге процессында үти, шул исәптән “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә куллана.

4. Һәр муниципаль хезмәткәр Кодексның нигезләмәләрен төгәл үтәргә тиеш, ә Россия Федерациясенең һәр гражданы муниципаль хезмәткәрдән төрле мөнәсәбәтләр нигезендә Кодекс нигезләмәләрен көтәргә хокуклы.

5. Кодексның максаты булып, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре, гражданнар алдындагы җаваплылыкны аңлап, үз вазыйфаи бурычларын намуслы һәм югары һөнәри дәрәҗәдә башкаруны, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең абруен ныгытуны, дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына халык ышанычын аклауны һәм муниципаль хезмәткәрләргә үз-үзеңне тоту тәртибенең бердәм нормаларын булдыруны тәэмин итү тора.

6. Кодекс муниципаль хезмәткәрләр үзләренең вазыйфаи бурычларын намуслы һәм югары һөнәри дәрәҗәдә башкаруны күздә тота.

7. Кодекс муниципаль хезмәт өлкәсендә әхлак нормаларына, җәмәгатьчелектә муниципаль хезмәткәрләренә ихтирамлы мөнәсәбәткә нигезләнгән үзара мөнәсәбәтләрне формалаштыруга нигез булып хезмәт итә, шулай ук муниципаль

хезмәткәрләренең иҗтимагый аң һәм әхлак, аларның үзконтроль институты буларак хезмәт итә

8. Муниципаль хезмәткәрләренең Кодекс нигезләмәләрен белүе һәм үтәве аларның хезмәт урынындагы тәртибен бәяләү критерийларыннан берсе булып тора.

## II. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенең төп принциплары һәм кагыйдәләре

9. Муниципаль хезмәттә булган Россия Федерациясе гражданнарының муниципаль хезмәткәрләрнең төп принциплары нигезе булып, хезмәт тәртибе тора.

10. Муниципаль хезмәткәрләре дәүләт, җәмгыять һәм гражданнар алдындагы җаваплылыкны аңларга тиешле:

а) дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарының нәтиҗәле эш булу максатыннан үз вазыйфаи бурычларын намуслы һәм югары һөнәри дәрәҗәдә башкаруы тора;

б) вазыйфаи бурычларны үтәгәндә расасына, милләтенә, теленә, дингә мөнәсәбәтенә һәм башка хәлләргә карамастан, кеше һәм гражданның хокукларын, иреген һәм законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

в) барлык физик һәм юридик затларга һәм оешмаларга бертигез, гадел мөнәсәбәт тәэмин итәргә, нинди дә булса иҗтимагый яисә дини берләшмәләргә, һөнәри яисә социаль төркемнәргә, гражданнарга һәм оешмаларга өстенлек бирмәскә һәм мондый берләшмәләргә, төркемнәргә, оешмаларга һәм гражданнарга карата аерым мөнәсәбәттә булмаска;

г) вазыйфаи бурычларны намуслы үтәүгә каршылык тудыра торган нинди дә булса шәхси, мөлкәти (финанс) һәм башка мәнфәгатьләр йогынтысына бәйле гамәлләр кылмаска;

д) үз һөнәри хезмәт эшчәнлегенә сәяси партияләр, башка иҗтимагый һәм дини берләшмәләр һәм башка оешмалар карарларының тәэсир итү мөмкинлеген калдырмыйча, нейтральлек сакларга;

е) гражданнар һәм вазыйфаи затларга мөрәҗәгать иткәндә, әдәпле һәм игътибарлы булырга;

ж) Россия Федерациясе халыкларының әхлакый гореф-гадәтләренә һәм традицияләренә карата ихтирамлы булырга;

з) төрле этник һәм социаль төркемнәрнең, шулай ук конфессияләрнең мәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алырга;

и) милләтара һәм конфессияара татулыкка ярдәм итәргә;

к) аның репутациясенә яисә муниципаль органның абруена зыян китерерлек конфликтлы вәзгыятьләргә юл куймаска.

л) дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлек эчтәлегенең төп мәгънәсе, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау.

м) үз эшчәнлеген дәүләт органы һәм җирле үзидарә органы вәкаләтләре чикләрендә башкарырга, үзара субординация һәм буйсынуны җирле үзидарә органы функциональ оештыру структурасында сакларга тиешле;

н) нинди дә булса һөнәри яки социаль төркемнәргә һәм социаль оешмаларга өстенлек бирмәскә, аерым гражданнарның, һөнәри яки социаль төркемнәрнең, оешмаларның йогынтысына бәйле булмаска;

о) ришвәтчелек белән бәйле хокук бозуларга этәрү максатыннан чыгып, нинди дә булса затларның җирле үзидарә органнары хезмәткәренә мөрәҗәгать итүенең барлык очраклары турында эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә яки башка дәүләт органнарына, прокуратура органнарына  җиткерергә;

п) башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәргә, бурычларны башкарырга, тыюларны бозмаска;

р) һөнәри этика һәм эштә үз-үзеңне тоту кагыйдә нормаларын үтәргә;

с) Россия, Татарстан Республикасы һәм башка дәүләтләр халыкларының гореф-гадәтләре һәм традицияләренә толерант мөнәсәбәттә булырга, төрле этник, социаль төркемнәр һәм конфессияләрнең мәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алырга, милләтара һәм конфессияара татулыкка ярдәм итәргә;

т) муниципаль хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын намуслы төстә үтәвенә шик тудырмаска, шулай ук җирле үзидарә органнары дәрәҗәсе яки абруена зыян салырдай низаглы хәлләргә кермәскә;

у) мәнфәгатьләр бәрелеше килеп чыгуга юл куймаска һәм килеп туган мәнфәгатьләр бәрелеше очракларын җайга салу буенча Россия Федерациясе законында күздә тотылган чаралар күрергә;

ф) шәхси мәсьәләләрне хәл иткәндә дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен хезмәт урыныннан файдаланмаска;

х) дәүләт органнары, җирле үзидарә органнарына һәм аларның җитәкчеләренә карата халык алдында фикер белдерүләрдән һәм бәяләмә бирүләрдән сагаерга, әгәр бу муниципаль хезмәткәрнең хезмәт вазыйфаларына кермәсә;

ц) дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары эше турында җәмгыятькә мәгълүмат җиткерү буенча массакүләм мәгълүмат бирүдән сакланырга;

ч) дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары эше турында җәмгыятькә мәгълүмат җиткерү буенча массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре эшчәнлегенә ихтирамлы мөнәсәбәттә булырга, шулай ук билгеләнгән тәртиптә дөрес мәгълүмат алуга ярдәм итәргә;

ш) дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрне, шулай ук вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә үзенә мәгълүм булган белешмәләрне, кирәк өчен төгәл мәгълүматларны тапшыру, Россия Федерациясенең халыкара килешүләрне, дәүләт һәм муниципаль бурычны, Россия Федерациясе территориясендә товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр, чит ил валютасында (шартлы акча берәмлегендә) акча әйләнешенең бәясен билгеләнешне массакүләм мәгълүмат чараларында фаш итүдән чикләнергә кирәк;

щ) үзе җаваплылыгындагы ресурслардан нәтиҗәлерәк файдалануга даими рәвештә омтылырга тиеш;

ы) Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының мәдәниятен, телләрен үстерү, саклап калу; мигрантларның социаль һәм мәдәни яраклашуын тәэмин итү,  төрле этник, социаль төркемнәр һәм конфессияләрнең мәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алырга, милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту, милләтара (халыкара) низагларны булдырмаска шартлар булдырырга;

э) барлык физик һәм юридик затларга һәм оешмаларга бертигез, гадел мөнәсәбәт тәэмин итәргә, нинди дә булса иҗтимагый яисә дини берләшмәләргә, һөнәри яисә социаль төркемнәргә, гражданнарга һәм оешмаларга өстенлек бирмәскә һәм мондый берләшмәләргә, төркемнәргә, оешмаларга һәм гражданнарга карата аерым мөнәсәбәттә булмаска.

11. Муниципаль хезмәткәрләр Россия Федерациясе Конституциясен һәм федераль законнарны һәм башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларын үтәргә бурычлы.

12. Муниципаль хезмәткәрләр үз эшчәнлекләрендә, сәяси һәм икътисади максаттан яисә башка сәбәпләр аркасында, законнарны һәм башка норматив хокукый актларны бозуга юл куярга тиеш түгел.

## III. Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы үз-үзеңне тоту стандарты

13. Муниципаль хезмәткәрләр билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе законнары нигезендә ришвәтчелекне булдырмас өчен төрле профилактик кисәтү чараларын күрергә бурычлы.

14. Муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, мәнфәгатьләр конфликтына китерердәй шәхси кызыксыну туу турында районның җирле үзидарә органы җитәкчесенә хәбәр итәргә һәм конфликтны булдырмау чараларын күрергә. Мәнфәгатьләр конфликтына китерүче барлык сәбәпләргә каршы торырдай чаралар күрергә һәм конфликт яки аның булу мөмкинлеге турында үзеңнең җитәкчеңне язма рәвештә искәртергә.

15. Муниципаль хезмәткәр Россия Федерациясе законы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә үзенә һәм гаилә әгъзаларына кагылышлы мәгълүматны, шул исәптән, аларның керемнәре, салым түләү объекты булган хосусый милекләре, милек характерындагы бурычлары турындагы мәгълүматны җиткерергә.

16. Муниципаль хезмәткәр ришвәтчелек белән бәйле хокук бозуларга этәрү максатыннан чыгып, нинди дә булса затларның җирле үзидарә органнары хезмәткәренә мөрәҗәгать итүенең барлык очраклары турында эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә яки башка дәүләт органнарына, прокуратура органнарына җиткерергә;

17. Муниципаль хезмәткәр бурычлы:

а) җирле администрация башлыгы вазыйфасын контракт буенча биләүче муниципаль хезмәткәрдән тыш, түләүле бүтән эш башкарса, яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) алдан язмача хәбәр итәргә тиеш.

б) эш бирүчедән язма рөхсәт алырга:

районның җирле үзидарә органы җитәкчесенең язма рөхсәтеннән тыш чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан финансланган түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Россия Федерациясе законы яки Россия Федерациясе халыкара килешүе тарафыннан башка гамәлләр каралмаган очракта;

район җирле үзидарә органы җитәкчесенең язма рөхсәтеннән башка чит илләрнең, халыкара оешмаларның бүләкләүләрен, мактау һәм махсус билгеләрне (фәнни исемнәрдән тыш), сәяси партияләрнең, башка җәмәгать оешмаларының һәм дини берләшмәләрнең мактау билгеләре һәм махсус исемнәрен алырга. Әлеге оешмалар

белән үзара бәйләнеш муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларына кергән очракта;

в) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затның кыйммәтле кәгазьләргә, акцияләргә (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләренә, пайларына) ия булуы мәнфәгатьләр конфликтына китерсә яисә китерергә мөмкин булса, күрсәтелгән зат үзенә караган кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләрен, пайларын) Россия Федерациясе гражданнар законы нигезендә ышанычлы идарә итүгә тапшырырга тиеш;

г) вазыйфаи бурычларны үтәү белән бәйле булмаган максатларга материаль-техник, финанс һәм башка муниципаль милек чараларын куллану.

18. Физик һәм юридик затлардан вазыйфаи дәрәҗәгә бәйле рәвештә яисә вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләкләүләр (бүләкләр, акчалата кызыксындыру, ссудалар, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачулар, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм башка бүләкләр) алырга рөхсәт ителми. Муниципаль хезмәткәрнең протокол чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле алынган бүләкләре муниципаль милек булып таныла һәм, Россия Федерациясенең Гражданлык кодексында билгеләнгән очраклардан тыш, үзе муниципаль хезмәт вазыйфасын били торган җирле үзидарә органына акт буенча тапшырыла.

19. Муниципаль хезмәткәр Россия Федерациясе законы нигезендә кабул ителгән нормаларын һәм таләпләрен саклаганда һөнәри эш кәгазьләрен үзгәртә ала һәм дәүләт органына яки җирле үзидарә органына тапшыра ала.

20. Муниципаль хезмәткәренә рөхсәт бирелмәгән килеш таратуга җавап бирергә тиеш булган яки вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә үзенә мәгълүм булган мәгълүматның сер булып калуын тәэмин итү буенча тиешле чаралар күрергә кирәк.

21. Җитәкче булып торган муниципаль хезмәткәр сәяси партияләр, башка иҗтимагый һәм дини берләшмәләр эшчәнлегендә муниципаль хезмәткәрләрне мәҗбүри катнаштыру очракларына юл куймаска тиеш.

22. Муниципаль хезмәткәр, башка муниципаль хезмәткәрләренә карата оештыру-боеру вәкаләтләренә ия булган муниципаль хезмәткәренә профессиональ осталык үрнәге, тел-теш тидергесез абруйлы белгеч булып тору, учреждениедә нәтиҗәле эшләү өчен уңай мораль-психологик климат булдыруга ярдәм итү тәкъдим ителә.

23. Муниципаль хезмәткәр, башка муниципаль хезмәткәрләренә карата оештыру-боеру вәкаләтләренә ия булган хезмәткәренә үз буйсынуындагы муниципаль хезмәткәре:

а) мәнфәгатьләр бәрелешен кисәтү һәм җайга салу чараларын күрергә;

б) коррупцияне кисәтү чараларын күрергә;

в) муниципаль хезмәткәрләрен сәяси партияләр һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегендә катнашуга мәҗбүриләү очракларына юл куймаска тиеш.

24. Муниципаль хезмәткәр, башка муниципаль хезмәткәрләренә карата оештыру-боеру вәкаләтләренә ия булган хезмәткәренә үз буйсынуындагы муниципаль хезмәткәрләренең коррупциячел тәртипкә юл куймавы буенча чаралар күрергә, үз тәртибе белән намуслылык, гаделлек үрнәкләрен күрсәтергә кирәк.

25. Муниципаль хезмәткәр, башка муниципаль хезмәткәрләренә карата оештыру-боеру вәкаләтләренә ия булган хезмәткәренә үз буйсынуындагы

муниципаль хезмәткәрләргә карата җаваплылыкны бозса, яки хезмәт тәртибе кагыйдәләре һәм әхлак принциплары боза торган гамәлләр кылса, Россия Федерациясе законнар нигезендә җаваплылык тота.

## IV. Муниципаль хезмәткәрләрнең этикасы һәм хезмәт тәртибенә тәкъдимнәре.

26. Муниципаль хезмәткәр, конституцион нигезләмәләрдән чыгып, кеше, аның хокуклары һәм ирекләре-иң зур хәзинә, гражданин шәхси тормышның кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серен, намусын, абруен, чын исемен саклауга хокуклы икәнен аңлап эш итәргә тиеш.

27. Муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаи бурычларны үтәгәндә чикләнергә тиешле:

а) теләсә кайсы төрдәге дискриминацион характердагы: яшь, раса, милләт, тел, гражданлык, социаль, мөлкәти яки гаилә хәленә карата, сәяси яки дини гамәлләрдән;

б) тупаслык, дорфалык, төрле гаепләүләрдән;

в) янаулардан, куркытулардан;

г) хезмәт киңәшмәләре, әңгәмәләр вакытында тәмәке тартудан;

д) төрле коуррупцион гамәлләрдән.

28. Муниципаль хезмәткәрләр үзләренең эш тәртибе белән коллективта эшлекле мөнәсәбәтләр, бер-берсе белән хезмәттәшлек урнаштырырга тиешләр.

Муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаи бурычларны үтәгәндә гражданнар белән әдәпле, игелекле, игътибарлы мөнәсәбәттә булырга тиешләр. Муниципаль хезмәткәрләрнең тышкы кыяфәте, аларның хезмәт вазыйфалары гражданнарга хөрмәт хисе уятырга, эшлекле стиль таләпләренә буйсынырга тиеш. Муниципаль хезмәткәрләрнең төп кагыйдәләре - тышкы кыяфәт һәм эшлекле кием. Төп элементы – эшлекле костюм.

V. Кодексның аерым нигезләмәләрен бозган өчен җаваплылык.

29. Муниципаль хезмәткәрләрнең Кодексның аерым нигезләмәләреннән тайпылган очракта комиссия утырышында гаепләү, ә Россия Федерациясе законнарында Кодексның аерым нигезләмәләрен бозган очракта юридик җаваплылык чаралары каралган.

Муниципаль хезмәткәрләрнең Кодекс нигезләмәләрен саклау аттестация, кадрлар резервын формалаштырган очракта, шулай ук тәртип кагыйдәләрен бозган очракта административ җәза карала.